**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 90-11 «26» октябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2017 елның 24 августындагы 132-20 номерлы «Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 30 мартындагы 184-27 нче, 2021 елның 25 июнендәге 59-8 нче номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указын үтәү йөзеннән

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2017 елның 24 августындагы 132-20 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә

әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә (2018 елның 30 мартындагы 184-27 нче, 2021 елның 25 июнендәге 59-8 нче номерлы карарлар редакциясендә)

1.1. 2 пунктның г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-биреш суммасы) муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артса, акча алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин